»Гөлназ» 49 нчы балаларның танып-белү-сөйләм үсешен өстенлекле
гамәлгә ашыручы гомумүстерелешле балалар бакчасы»
муниципаль бюджет мәктәпкәчә белем
бирү учреждениесе

# “ЮЛДА УЯУ БУЛЫГЫЗ”

# ЮЛ ЙӨРУ КАГЫЙДӘЛӘРЕН ӨЙРӘНУ БУЕНЧА УРТАНЧЫЛАР ТӨРКЕМЕНДӘ КҮҢЕЛ АЧУ КИЧӘСЕ.

Тәрбиячеләр:
Галиаскарова Розалия Гумеровна
Салихова Люзә Тафтиловна
Гарипова Сания Наиловна

**Максат.**

1. Уен формасында балаларның юл йөрү кагыйдәләре турындагы белемнәрен ныгыту.
2. Юл йөрү кагыйдәләрен бозу нәрсәгә китергәне турында аңлатма бирү.
3. Юлларда сак булуны, игътибарлыкны тәрбияләү. Алынган белемнәрне уеннарда, көнлек тормышта куллана белергә йөрәтүне дәвам итү.

**Алдан эшләнгән эш.**

Шигырьләр, җырлар өйрәнү. Юл йөрү кагыйдәләрен, юл билгеләрен өйрәнү һәм кабатлау.

**Җиһазлау.** Юл билгеләре макетлары, аудиоязмалар.

**Кичә барышы:**

**1 Алып баручы:**

Исәнмесез,кадерле балалар,килгән кунаклар.Кичәбезне ачып җибәрергә рөхсәт итегез.Без бүген сезне ”Юлда уяу булыгыз”дигән уенга чакырабыз.Уеныбызны юл йөрү кагыйдәләренә багышладык.Без бу теманы юкка гына алмадык.Соңгы вакытта юллардагы машиналар саны көннән- көн арта,шулай ук юл һәлакәте дә арта.

**2 Алып баручы** Безнең илнең юллары меңләгән километрларга сузылган. Иртә дә, төн дә шул юллар буенча йөк һәм җиңел машиналар, автобуслар, троллейбуслар хәрәкәт итә. Кайвакыт без җәяүле, ә кайвакыт пассажир булабыз. Шуның өчен дә безгә юл йөрү кагыйдәләрен белү бик мөһим.

**Бала**:

Юл кагыйдәләре бик күп,
Белергә иде барсын.
Ләкин иң кирәклеләре
Һәрчак исеңдә булсын
Сәламәт булыйм дигән бала
Юлларда уйнамасын.



**1 Алып баручы:**

Бер әкияти урманда куян яшәгән**.** Ул юл йөрү кагыйдәләрен өйрәнергә  бер дә яратмаган. Аңа үләндә тәгәрәп ятарга һәм үзенең җырларын җырларга бик ошаган. (Портфелен болгый-болгый, җырлый-җырлый куян килеп чыга)

**Куян** Ямансу түгел миңа,

Җырлыймын җырларымны

Ля-ля-ля, ля-ля-ля. (Керепидәнгә утыра)

**2 Алып баручы:** Һәркем юл йөрү кагыйдәләрен белергә тиеш. Юлны светофорның яшел төсенә яки җәяүле аркылы чыгу юлыннан чыгарга кирәк. Юлга баскач, уңга һәм сулга кара.

(Куян борын астыннан җырлап утыра)

**1 Алып баручы:**

**-** Куян!Машина йөргән юлда уйнарга ярыймы? (Куян аннан нәрсә сораулары турында аңламый)

– Син тагын безне ишетмисең. Юлда синең белән берәр куркынычсызлык килеп чыкмасын дип куркам.

**Куян:** -Хи-Хи! Бер нәрсә дә булмый минем белән! Мин бар нәрсәне дә беләм!

**2Алып баручы:**

-Ай-яй! Нинди мактанчык син!  балалар! Куян кебек игътибарсыз булырга ярамый! Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес үтәргә кирәк.

**Куян:**

– Миңа нигә кирәк инде ул, мин кагыйдәләрсез дә булдырам (чыгып йөгерә)

(Машина бик каты итеп тормоз тоткан тавыш ишетелә)

**Куян:**

– Ай-ай-ааааай! Коткарыгыз! Шул кадәр авырта!

(Табиб килеп чыга, куянны карый, аягын бәйли)

**Табиб:** -Ай-яй Куян тыңламаулыгын нәрсәгә китерде.Юл йөрү кагыйдәләрен дөрес үтәргә кирәк, юлдан чыкканда игътибарлы бул, юкса фаҗига да килеп чыгарга мөмкин.

**1Алып баручы:**

**-**Мин бит сине кисәткән идем, тыңлаусыз куян.

**Куян :**

**-**Мин  юл йөрү кагыйдәләрен  өйрәнермен,
 игътибарлы булырмын.

**2.Алып баручы:**

– Балалар, куянга ышанабызмы? (Әйе).



**1Алып баручы :**Балалар светофор –юлда иң кирэкле билге.Ул булмаса –юлда ни булыр иде.Хэзер балалар светофор турында шигырь сөйләрләр.

1.Данис”Светофорның өч күзе”.

2.Алинә”Светофор”

**2Алып баручы:** Балалар, сез нинди светофорлар беләсез?ниндиләрен күргәнегез бар? (әңгәмә) 2 төрле –берсе машиналар өчен -3 төсле-кызыл,сары,яшел. 2нче светофор-җәяүлеләр өчен-2 төсле:кызыл,яшел. Безнең балалар светофор турында җыр да беләләр.

**Җыр**

**1Алып баручы:**

**-**Балалар! Светофор безгә һәрвакыта ярдәмгә килә алмый! Ул вакытта безгә ярдәмгә аның якын дуслары – юл билгеләре килә.Хәзер балалар шул билгеләр турында сөйләп китәрләр, син, куян, игътибар б-н тыңла.

**Бала:** Урам аркылы ята
Юллы-юллы ак тасма
Җәяүле тик шуннан үт
Һич исеннән чыгарма
**(Җәяүле юлы)**

**Бала:** Кызыл түгәрәктә кеше
Әйтә кебек шул хакта
Юл юк монда җәяүлегә
Икенче юлдан атла
**(Җәяүлегә юл юк)**



**Бала:**  Тора урамда армый
Як-якка карый-карый
Язын-җәен,кыш һәм көз
Кызыл,сары ,яшел күз
**(машиналар өчен Светофор)**
**Бала:** Җир астыннан юллар  юк дип
Җырлыйлар гына җырда
Җир астыннан үтәбез без
Иркенләп,курыкмыйча.
**(Җир астыннан чыгу билгесе)**
**Бала:** Ике көпчәк ияре бар
Руль,педаль, рамда
Ике аяк шәп эшлиләр
Йөртеп барсак урамда
Бу билгене һәрвакытта
Алдан кирәк күрергә
Кызыл түгәрәк эчендә
Рөхсәт бирми йөрергә.
**(Велосипедта йөрү тыела)**
**Бала:** Кызыл түгәрәк эченә
Ясап куелган ак “кирпич
Ничек кенә ашыксаң да
Үтә алмассың һич
**(Үтү тыела)**





**2Алып баручы** Менә куянкай юл билгеләрен танырга өйрәндеңме инде.Юлда игътибарлы булырсыңмы?

Куянкай без сиңа кагыйдәләрне  тагын да ныграк өйрәнү өчен “Юл әлифбасы” дигән китап бүләк итәбез.

**Куян**  рәхмәт сезгә миңа юл билгеләрен танырга өйрәтүегез өчен.Мин хәзер игътибарлы булырмын.Мина кайтырга кирәк.Сау булыгыз.

**1Алып баручы:** Сау бул куянкай.

– Ә хәзер, балалар, әзрәк уйнап, ял итеп алыйк.

***Уен: “Светофор”***

Алып баручы төсләр күрсәтә. Балалар түгәрәккә басалар:

Кызыл төс – берни  эшләмиләр

Яшел төс – тыпырдыйлар

(Балалар урыннарына утыралар)

**2Алып баручы:**

– Булдырдыгыз, ! Ә хәзер мин сезгә тагын бер уен тәкъдим итәм.

-Юлны кызыл төскә чыгарга**........(ярамый)**

- Юл кырыенда туплы уйнарга**........(ярамый)**

- Юл кагыйдәләрен үтәргә **...............(ярый)**

-Светофорда яшел ут янганда юл аркылы чыгарга  **........(ярый)**

-Юлны теләсә кайдан чыгарга ...........(**ярамый)**

**-**Юлны җәяүле юлы  аша чыгарга ..........(**ярый)**

**1Алып баручы** Безнең балалар бик матур бию дә өйрәнделәр. Хәзер биеп күрсәтерләр.

**Бию**

**2Алып баручы** Ә хәзер Марсель б-н Эльнара урамда ничек йөрергә кирәклеге турында шигырь сөйләп китәрләр.

**Шигырь”Урамда ничек йөрергә”**

**1Алып баручы:** Сез барлык нәрсәне дә исегездә калдырдыгыз һәм юл йөрү кагыйдәләрен бозмассыз дип ышанам.

**2Алып баручы.** Юл уяуларны, сак булганнарны ярата.Моны беркайчан да истән чыгармыйк.

Юл йөрү кагыйдәләрен
Төгәл үтәп йөрсәгез,
Юл чатында басып торып
Светофорны күрсәгез
Шул чагында бәла-каза
Сезне читләтеп үтәр.









Игътибарыгыз өчен рәхмәт!